| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 октября 2025 г. с.Шалты № 8

Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Башкарма комитетының 28.10.2024 № 5 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2025 ел, № 304-ФЗ Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Башкарма комитетының 28.10.2024 № 5 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» 2 бүлегендә:

2.5.1 пунктының 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү зарур» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү зарур» сүзләренә алмаштырырга;

2.16.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) бердәм портал ярдәмендә орган тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган машинада укыла торган форматтагы электрон документ алырга.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе З.Х. Фаткуллин